СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**23 октябрь, 2024 ел** **№ 458**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Гражданнарның Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 26 маендагы 147 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «раслау хакында» 2017 елның 26 маендагы 147 номерлы карары (Советның 17.04.2019 №291 карары редакциясендә) белән расланган Гражданнарның Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.5 пунктындагы 1) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма формада яисә электрон документ формасында, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы» (алга таба - Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелгән тәкъдим, гариза яисә шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате».

1.2. 5 бүлекнең 5.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгать законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан мәҗбүри рәвештә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), әгәр җавап электрон документ формасында җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресын яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресын, һәм әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, почта адресын күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле

документларны һәм материалларны кушымта итеп электрон формада бирергә яки күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.»

1.3. 8 бүлекнең 8.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8.4. Мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яисә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча, ул аннан файдаланганда, электрон документ формасында һәм язма рәвештә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамөтдинов